# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында" 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә сайланган, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль закон, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка законнары белән каралган закон чыгару вәкаләтләрен һәм башка вәкаләтләрне гамәлгә ашырырга вәкаләтле халык вәкиле Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты була.";

2) 3 статьяда "әлеге Законның 4 статьясындагы 1 һәм 3 пунктларында каралган" сүзләрен "әлеге Законның 4 статьясында каралган" сүзләренә алмаштырырга;

3) 4 статьяда:

а) 1 пунктның "б" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"б) аңа Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи заты (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) вәкаләтләрен бирү, аны федераль законнар нигезендә депутат статусы белән бергә биләү мөмкин булмаган вазыйфага сайлап кую, раслау яисә билгеләп кую;";

б) 2 пунктның "б" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"б) әлеге Законның $7^1$ статьясындагы 4 – 6 пунктларында күрсәтелгән таләпләрне үтәмәү.";

в) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

"$2^1$. Әлеге статьяның 1 пунктында һәм 2 пунктындагы "б" пунктчасында каралган нигезләмәләр буенча депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советының чираттагы утырышында депутат вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килгәннән соң Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карала.";

г) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Депутат вәкаләтләрен әлеге статьяның 1 пунктында һәм 2 пунктындагы "б" пунктчасында каралган нигезләр буенча туктату Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән рәсмиләштерелә, анда депутат вәкаләтләрен туктату көне күрсәтелә. Әлеге статьяның 2 пунктындагы "а" пунктчасында каралган очракта депутатның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы законнарын кабул итүгә, шулай ук аның утырышта карарлар кабул итү юлы белән гамәлгә ашырыла торган башка конституциячел вәкаләтләрен башкаруга кагылышлы вәкаләтләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советы таркатылган көннән туктатыла.";

д) түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

"4. Депутат вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, барлыкка килгән вакантлы депутат мандатын биләү законнарда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.";

4) 5 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5 статья. **Депутат таныклыгы һәм күкрәк тамгасы**";

б) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Депутат таныклыгы һәм күкрәк тамгасы турындагы нигезләмәләр, аларның үрнәкләре һәм тасвирламалары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән раслана.";

5) 6 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

"$4^1$. Әгәр депутат эшчәнлеге Татарстан Республикасы Дәүләт Советында профессиональ даими нигездә башкарылса, күрсәтелгән депутат граждан яисә җинаять эше йә административ хокук бозу турындагы эш буенча яклаучы яки вәкил (законлы вәкил очрагыннан тыш) буларак катнаша алмый.";

б) 5 һәм 8 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

6) 7 статьяның 1 пунктында:

а) түбәндәге эчтәлекле "$ж^1$" пунктчасын өстәргә:

"$ж^1$) депутат мөрәҗәгате җибәрү;";

б) "к" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"к) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында фракцияләр һәм башка депутат берләшмәләре эшендә катнашу.";

7) $7^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"$7^1$ статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Советында фракцияләр һәм башка депутат берләшмәләре**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатларның республика исемлеге составында сайланган депутатлар берләшмәсе фракция була. Кандидатларның тиешле республика исемлеге составында сайланган барлык депутатлар фракциягә керәләр. Фракциягә шулай ук бермандатлы сайлау округлары буенча сайланган депутатлар һәм әлеге статьяның 7 пунктында күрсәтелгән сәяси партия кандидатларының республика исемлеге составында сайланган депутатлар да керә ала.

2. Бермандатлы сайлау округлары буенча сайланган депутатлар, шулай ук әлеге статьяның 7 пунктында күрсәтелгән сәяси партия кандидатларының республика исемлеге составында сайланган депутатлар фракцияләр булып тормаган депутат берләшмәләре төзергә хокуклы.

3. Фракцияләрне һәм башка депутат берләшмәләрен төзү, теркәү һәм аларның эшчәнлек тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты белән билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән кандидатларның республика исемлеге составында сайланган депутат әлеге статьяның 1 пункты нигезендә үзе тора торган фракциядән чыгарга хокуклы түгел. Күрсәтелгән депутат үзе депутат итеп сайланган кандидатларның республика исемлеге составындагы сәяси партиянең генә әгъзасы була ала.

5. Бермандатлы сайлау округы буенча сайланган һәм фракциягә керүче депутат яисә әлеге статьяның 7 пунктында күрсәтелгән сәяси партия кандидатларының республика исемлеге составында сайланган һәм фракциягә керүче депутат үзе фракциягә кергән сәяси партиянең генә әгъзасы була ала.

6. Әлеге статьяның 7 пунктында күрсәтелгән сәяси партия кандидатларының республика исемлеге составында сайланган, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында фракциясе булган сәяси партиягә кергән депутат әлеге фракциягә керә һәм аннан чыгарга хокуклы түгел.

7. Сәяси партия бетерелүгә яисә үзгәртелүгә бәйле рәвештә сәяси партия эшчәнлеге туктатылган очракта, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында аның фракциясе эшчәнлеге, шулай ук әлеге фракциядә депутатларның әгъза булып торуы юридик затларның бердәй дәүләт реестрына тиешле язма кертелгән көннән туктатыла.";

8) 8 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

"5. Депутат сайлау округында үз эше турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына мәгълүмат бирә. Әлеге мәгълүматны бирү тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан раслана.";

9) 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. **Депутатның депутат этикасы кагыйдәләрен үтәве**

Депутат Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан расланган депутат этикасы кагыйдәләрен үтәргә тиеш. Депутатның депутат этикасы кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыгы күрсәтелгән кагыйдәләр һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Регламенты белән билгеләнә.";

10) 10 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

11) 13 статьяда:

а) 1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында депутат гарызнамә белән үз компетенциясенә керүче мәсьәләләр буенча Татарстан

Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенә, Татарстан Республикасы Премьер-министрына, Татарстан Республикасы министрларына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан төзелеп яисә сайланып куела торган башка органнар (судлардан тыш) җитәкчеләренә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2. Депутат гарызнамәсе – депутатның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары белән депутат гарызнамәсе дип танyла торган мөрәҗәгате. Депутат гарызнамәсе турындагы тәкъдим язма рәвештә кертелә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты белән билгеләнгән тәртиптә игълан ителә. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының әлеге мәсьәләне хәл итүе карар белән рәсмиләштерелә.";

б) 5 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

"7. Әгәр җавап депутат гарызнамәсенең асылы буенча бирелмәсә йә гарызнамәгә вәкаләтсез зат имза салган булса, депутат тәкъдиме буенча гарызнамәгә җавап Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы утырышында каралырга мөмкин. Депутат гарызнамәсен карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы карар кабул итәргә мөмкин.";

12) 14 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"14 статья. **Депутат тәкъдимнәре**

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышларында депутат тарафыннан язма рәвештә кертелгән тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советы органнары тарафыннан карала йә карау өчен дәүләт органнарына һәм вазыйфаи затларга җибәрелә.

2. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән депутат тәкъдимнәре җибәрелгән дәүләт органнары һәм вазыйфаи затлар тәкъдимнәрне бер айдан да соңга калмыйча карарга һәм нәтиҗәләр турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына һәм депутатка хәбәр итәргә тиеш. Тәкъдим кире кагылган очракта, нигезле җавап бирелә.

3. Федераль дәүләт хакимияте органнары һәм аларның вазыйфаи затлары әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән депутат тәкъдимнәрен карауны федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашыралар.";

13) түбәндәге эчтәлекле $14^1$ статья өстәргә:

"14[1] статья. **Депутат мөрәҗәгате**

1. Депутатның дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга һәм иҗтимагый берләшмәләргә, шулай ук вазыйфаи затларга күрсәтелгән органнарның һәм вазыйфаи затларның компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча аның депутат эшчәнлегенә бәйле мәгълүмат һәм белешмәләр алу максаты белән язма рәвештә мөрәҗәгать итүе депутат мөрәҗәгате дип санала.

2. Депутат мөрәҗәгате депутат бланкында рәсмиләштерелә һәм депутат тарафыннан мөстәкыйль җибәрелә.

3. Үз компетенцияләре нигезендә дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр, вазыйфаи затлар тарафыннан алынган депутат мөрәҗәгате мөрәҗәгатьне теркәгән көннән алып җиде көн эчендә карала, һәм күрсәтелгән сроктан соңга калмыйча депутатка соратыла торган мәгълүмат яисә белешмәләр бирелә. Бу очракта дәүләт яисә коммерция серен тәшкил итүче белешмәләр федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелә.

4. Аерым очракларда, әгәр депутат мөрәҗәгате буенча өстәмә тикшерү үткәрү яисә нинди дә булса өстәмә материаллар соратып алу кирәк булса, мөрәҗәгатьне карау срогы аны теркәгән көннән алып 30 көнгә кадәр озайтыла. Әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затлар депутатка аның мөрәҗәгатен карау срогы озайтылу турында язма хәбәр бирергә тиеш.

5. Федераль дәүләт хакимияте органнарының вазыйфаи затлары депутат мөрәҗәгатен федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карыйлар.

6. Депутат мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне карауда, шул исәптән коллегиаль органнарының ябык утырышларында да, турыдан-туры катнашырга хокуклы. Карау көне турында депутатка өч көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителергә тиеш.

7. Депутат мөрәҗәгатенә җавапка мөрәҗәгать җибәрелгән вазыйфаи зат йә шуңа вәкаләтле зат имза салырга тиеш.

8. Әгәр җавап җибәрелгән депутат мөрәҗәгатенең асылы буенча бирелмәсә йә мөрәҗәгатькә җавапны вәкаләтсез зат имза салган булса, депутат тәкъдиме буенча аның мөрәҗәгатенә җавап Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты нигезендә мөрәҗәгать җибәрелгән вазыйфаи зат катнашында Татарстан Республикасы Дәүләт Советының профильле комитеты утырышында каралырга мөмкин.";

14) түбәндәге эчтәлекле 14[2] статья өстәргә:

"14[2] статья. **Депутат тикшерүе**

1. Депутат тикшерүе – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының контроль вәкаләтләрен гамәлгә ашыру рәвеше. Депутат, депутатлар төркеме, Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат берләшмәсе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитеты таләбе белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы үз карамагындагы мәсьәлә буенча депутат тикшерүе үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.

2. Депутат тикшерүен үткәрү Татарстан Республикасы Дәүләт Советының тиешле комитетына яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының махсус төзелгән комиссиясенә йөкләнә.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары депутат тикшерүе үткәрүдә ярдәм итәргә, депутат тикшерүе үткәрү өчен кирәкле тиешле документларны һәм материалларны бирергә тиеш. Күрсәтелгән документларны һәм материалларны бирү дәүләт сере һәм закон белән саклана торган башка сер турында Россия Федерациясе законнарын үтәп гамәлгә ашырыла.

4. Депутат тикшерүе үткәрелгәндә, гражданнарның хосусый тормышына тыкшыну, гражданнарның хосусый тормышы кагылгысызлыгын бозу рөхсәт ителми.

5. Депутат тикшерүе нәтиҗәләре буенча тикшерү үткәрү йөкләнгән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитеты яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының махсус төзелгән комиссиясе дәлилләнгән бәяләмә төзи, ул Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында карала. Карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карар кабул итә.";

15) 15 статьяның 2 пунктында "эшләү тәртибендә" сүзләрен "утырышында" сүзенә алмаштырырга;

16) 16 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"16 статья. **Депутатның вазыйфаи затлар тарафыннан кабул ителүгә хокукы**

1. Депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча депутат Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, барлык милек рәвешендәге оешмаларның җитәкчеләре һәм башка вазыйфаи затлары тарафыннан кичектергесез кабул ителү хокукыннан файдалана.

2. Депутат вазыйфаи затка турыдан-туры яисә вазыйфаи затның кабул итү бүлмәсе (секретариаты) аша телдән йә язмача мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3. Телдән мөрәҗәгать иткән очракта кабул итү вакыты вазыйфаи зат тарафыннан депутат белән килештереп, ә депутат язмача мөрәҗәгать иткән очракта кабул итү вакыты депутат мөрәҗәгатен алган мизгелдән өч көннән дә соңга калмыйча вазыйфаи зат тарафыннан билгеләнә.

4. Депутатны өч көн эчендә кабул итү мөмкинлеге булмаганда, вазыйфаи зат, депутат белән килештереп, башка вакыт билгели.";

17) 17 статьяның 2 һәм 3 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

18) 18 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"18 статья. **Депутатның хезмәт хокуклары гарантияләре**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында профессиональ даими нигездә эшләүче депутатның вәкаләтләр чоры гомуми һәм өзлексез хезмәт стажына, белгечлеге буенча эш стажына, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм муниципаль хезмәт стажына кертеп исәпләнә.";

19) 19 статьяның 2 пунктында "1500 сум күләмендә" сүзләрен "5000 сум күләмендә" сүзләренә алмаштырырга;

20) 22 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"22 статья. **Татарстан Республикасы Дәүләт Советында профессиональ даими нигездә эшләүче депутатка хезмәт урыны бирү**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советында профессиональ даими нигездә эшләүче депутатка үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы бинасында мебель, оештыру техникасы һәм элемтә чаралары белән җиһазландырылган хезмәт урыны бирелә.";

21) 23 статьяның 1 пунктындагы икенче җөмләне төшереп калдырырга;

22) 24 статьяның 5 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

23) 25 статьяның 1 пунктында "торак мәйданы" сүзләрен "торак урыны" сүзләренә алмаштырырга;

24) 27 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"27 статья. **Депутат эшчәнлеген матди-техник тәэмин итү тәртибе һәм шартлары**

1. Депутатка үзе сайланган бермандатлы сайлау округында йә әлеге Законның 8 статьясындагы 1 пункты нигезендә депутатка билгеләнгән сайлау округында депутат вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан, депутат белән килештереп, транспорт чаралары, мебель, элемтә чаралары һәм кирәкле оештыру техникасы белән җиһазландырылган саклана торган аерым урын бирелә, шулай ук әлеге Законда каралган үз вәкаләтләрен башкару өчен башка шартлар тәэмин ителә. Депутатка депутат вәкаләтләрен башкару өчен күрсәтелгән чараларны бирү тәртибе һәм шартлары Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан раслана.

2. Сайлау округында депутат эшчәнлеген матди тәэмин итүгә бәйле чыгымнар тиешле документлар нигезендә әлеге акчаларны алга таба, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чыгымнары сметасына кертеп, Татарстан

Республикасы Дәүләт Советы бюджетыннан каплау юлы белән муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан түләнә.

3. Депутатның элемтә чараларыннан файдалануга, билетлар сатып алуга һәм рәсми затлар, делегацияләр өчен заллардан файдалануга бәйле чыгымнары депутатка әлеге Законның 23 һәм 24 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советын тотуга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы билгеләгән тәртиптә һәм лимитлар чикләрендә түләнә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутатлар эшчәнлеген матди-техник тәэмин итү тәртибе Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты нигезендә билгеләнә.";

25) 28 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"28 статья. **Депутат ярдәмчеләре**

1. Депутат иң күбе биш ярдәмче тотарга хокуклы.

2. Депутат ярдәмчесе эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары һәм тәртибе депутат ярдәмчесе турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы раслый торган нигезләмә белән билгеләнә.

3. Депутат ярдәмчесенә билгеләнгән үрнәктәге таныклык бирелә.";

26) 29 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

27) 30 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"30 статья. **Депутат эшчәнлеген гамәлгә ашыруда каршылыклар тудырган өчен җаваплылык**

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның һәм иҗтимагый берләшмәләрнең вазыйфаи затлары әлеге Закон нигезләмәләрен үтәмәгән өчен, шул исәптән депутат гарызнамәләренә һәм мөрәҗәгатьләренә мәгълүмат һәм җаваплар бирүнең бу Законда билгеләнгән срокларын һәм тәртибен үтәмәгән өчен, белә торып ялган мәгълүмат биргән өчен, мәгълүмат бирүдән законсыз баш тарткан өчен, аны бирүдән читләшкән өчен, депутатларны кабул итү кагыйдәләрен бозган өчен, законнарда каралган җаваплылык билгеләнә.".

**2 статья**

1. Әлеге Закон, 1 статьясындагы 19 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 19 пункты 2010 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2010 елның 29 июне
38- ТРЗ